**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**“ЗЕЛЁНАЯ РОЩА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**ИЛЛЕ ӨЧЕНЧЕ СЕССИЯ**
**1нче КАРАР**

Зелёная Роща авылы 2019 ел, 19 июнь

**Зелёная Роща авыл Советының**
**2018 елның 17 октябрендә булып узган**
**45нче сессиясендә кабул ителгән**
**“Җир салымы турында”гы**
**1нче kararга үзгәрешләр кертү турында**

2019 елның 15 апрелендә кабул ителгән “Россия Федерациясенең Салым турындагы кодексының икенче өлешенә һәм “Россия Федерациясе Салым Кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законның 9нчы маддәсенә үзгәрешләр кертү турында”гы №63-ФЗ Федераль Законына һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Зелёная Роща авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**Зелёная Роща авыл җирлеге Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Зелёная Роща авыл Советының 2018 елның 17 октябрендә булып узган 45нче сессиясендә кабул ителгән “Җир салымы турында”гы 1нче карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6нчы пунктның беренче абзацында “физик затлар” дигән сүзләрне алып ташларга (үзгәреш 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә).

1.2. 2нче пунктның дүртенче абзацын яңа басмада бәян итәргә:

– шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелек эше алып бару өчен алынган, эшмәкәрлек эшчәнлеге алып барылмый торган җир кишәрлекләренә, һәм шулай ук 2017 елның 29 июлендә кабул ителгән “Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык я яшелчәчелек эше алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы №217-ФЗ Федераль Законында каралган җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә – 0,3%.

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында күрсәтергә һәм “Интернет” челтәрендә Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**“Зелёная Роща авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **Д.М. Хикмәтов**